**ТАТАРСТАН**
**РЕСПУБЛИКАСЫ**
**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ ӘМӘКӘЙ**
**АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АМИКЕЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ**
**МУСЛЮМОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА**

*423985, Р.Т. Муслюмовский район, с.Амикеево, ул.И.Фаррахова-34,*
*Amik.Mus@tatar.ru тел. (8-85556) 3-30-33*

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ**
**V ЧАКЫРЫЛЫШ VII УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 9**

***Әмәкәй авылы*** ***“19” нчы март, 2026 нчы ел***

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлеге Советының 2018 елның «28» ноябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 71 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләрене Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 №425-ФЗ Федераль законына таянып Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы прокурорының 02.03.2026 елгы протестын үтәү йөзеннән 02-08-01-2026, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Әмәкәй авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Әмәкәй авыл җирлеге Советының 2018 елның «28» ноябрендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 71 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1 2 пунктның 4 пунктчасындагы 5 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым сал объектлары, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзеле бетмәгән объектлардан тыш"

2.Карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталынд түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Мөсли муниципаль районының рәсми сайтында чыгару.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Татарстан Республикасы**
**Мөслим муниципаль районы**
**Әмәкәй авыл җирлеге башлыгы** **И.И.Шакирҗанова**